| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** — **КАРАР**

22.07.2020 — Казан шәһәре — № 66-48/тп-2020

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020 елга тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек бирәмлегенә исәпләгәндә «РСК» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 6-141/тп номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы, «Җылылык белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик ялгау), җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтләрдән дискриминацияле булмаган рәвештә файдалану мөмкинлеге, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын үзгәртү һәм көчләрен югалткан дип тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплап чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020 елга тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә исәпләгәндә «РСК» акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) өчен түләү билгеләү турында» 2019 елның 18 декабрендәге 6-141/тп номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

«кушымтага» сүзен «1 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2. Әлеге карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмый торган объектын «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлеге исәбеннән түләү билгеләргә.»

кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 2019
елның 18 декабрендәге 6-141/тп
номерлы карарына 1 нче кушымта»;

түбәндәге эчтәлекле 2 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының 2019
елның 18 декабрендәге 6-141/тп
номерлы карарына 2 нче кушымта

## Мөрәҗәгать итүченең тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмый торган объектын «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына тоташтыру (технологик ялгау) очрагында тоташтырыла торган җылылык йөкләнешенең егәрлек берәмлегенә түләү

мең сум/Гкал/сәг (НДС исәпкә алмыйча)

| Тәртип саны | Аталышы | Билгесе |
|---|---|---|
| 1 | Мөрәҗәгать итүчеләрнең объектларын тоташтыру чараларын үткәрүгә чыгымнар ($П_1$) | 1,810 |
| 2 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше сәгатенә 0,1 Гкал артык һәм сәгатенә 1,5 Гкал артмаган объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык челтәрләре ясауга (үзгәртеп коруга) (җылылык пунктлары төзүдән (үзгәртеп корудан) тыш) чыгымнар, ($П_{2.1}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир өслегеннән) салу | |
| 2.1.1 | 50-250 мм | - |
| 2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.1.3 | 401-550 мм | - |
| 2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | – |
| 2.2 | Җир астыннан салу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал итеп салу | |
| 2.2.1.1 | 50-250 мм | 1 803,986 |
| 2.2.1.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401-550 мм | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2.1.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 2.2.2 | канал итмичә салу | |
| 2.2.2.1 | 50-250 мм | - |
| 2.2.2.2 | 251-400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401-550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551-700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм күбрәк | - |
| 3 | Гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яисә җылылык энергиясе чыганакларыннан мөрәҗәгать итүчеләрнең, техник тоташтыру мөмкинлеге булганда, тоташтырыла торган җылылык йөкләнеше 1,5 Гкал/сәг артып киткән объектларын тоташтыру нокталарына кадәр җылылык пунктлары төзүгә (үзгәртеп коруга) чыгымнар ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | -» |

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.П.Борисова